# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№1**

**14 ноябрь 2025 ел.**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлегенең Победа торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2025 елның 14 ноябрендәге гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча түбәндәге сорау буенча йомгаклау беркетмәсе төзелде:

Сез "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлегенең Победа торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, 2 төркем инвалидлардан көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнарыннан тыш, 2026 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы?

1) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (энергияне саклый торган лампалар, электр товарлары, махсус җайланмалар һәм башка материаллар сатып алу һәм урнаштыру, яктырткычларны һәм урам яктырткычларын алмаштыру, урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү);

2) су белән тәэмин итү һәм су түгү системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Победа поселогы, Үзәк ур., 11 һәм 13, 18 йортлар адресы буенча күпфатирлы торак йортларның су түгү системаларын ремонтлау);

3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Татарстан урамында вак таш сатып алу, төяү, ташу, салу)

4) торак пунктның башка территорияләрен тезекләндерү (юлларны җәйге-кышкы чорда карап тоту).

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә яраклы рәвештә: сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 450 катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә 233 кеше катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" - 233 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" - 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Азнакай муниципаль районының авылы җирлегенең Победа торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре дерес дип танырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлегенең Победа торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, 2 төркем инвалидлардан көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнарыннан тыш, 2026 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы?

1) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (энергияне саклый торган лампалар, электр товарлары, махсус җайланмалар һәм башка материаллар сатып алу һәм урнаштыру, яктырткычларны һәм урам яктырткычларын алмаштыру, урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү);

2) су белән тәэмин итү һәм су түгү системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Победа поселогы, Үзәк ур., 11 һәм 13, 18 йортлар адресы буенча күпфатирлы торак йортларның су түгү системаларын ремонтлау);

3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Татарстан урамында вак таш сатып алу, төяү, ташу, салу)

4) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны җәйге-кышкы чорда карап тоту).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» http://aznakaevo.tatar.ru. һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан: Победа п., Үзәк ур,30 мәгълүмат стендларында, урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Вахит авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Вахит авыл җирлеге Башлыгы Г.И. Әскәрова